**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**Салманского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Салман авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Адрес: 422874, Республика Татарстан, Алькеевский район, с. Салманы, ул. Молодёжная, д.12.
тел.: : 8 (84346) 72-2-38

Адресы: 422874, Татарстан Республикасы, Әлки районы,
Салман авылы, Яшьләр ур., 12.
тел.: 8 (84346) 72-2-38

## КАРАРЫ

2020 елның 23 сентябре № 6

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга( соңгы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законына карата, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85, 86 статьясы нигезендә Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 11 октябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә хупларга.

2.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын махсус җиһазланган мәгълүмати стендларда һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http://pravo.tatarstan.ru/ порталында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Гайфуллина Лейсан Фарид кызы -Салман авыл җирлеге Советы депутаты;
- Махмутов Альберт Фирдинат улы -Салман авыл җирлеге Советы депутаты;
- Нурутдинов Дамир Нургаяз улы -Салман авыл җирлеге Советы депутаты;

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча 2020 елның 15 октябрендә Салман авыл җирлеге Советы бинасында җәмәгать тыңлаулары үткәрергә.

5. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге советы депутатлары һәм гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.

6.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты үтәлешен контрольдә тотуны, карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карауны эшче төркемгә йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Салман
Авыл җирлеге Башлыгы: Л.Ф.Гайфуллина.

Советының карарына
Салман авыл җирлеге
Советының 2020 елның
23 сентябрендәге 6
номерлы карарына1 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:**
«16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү.»;

**6 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;»;

**47 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**
« - участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү.»;

**47 статьяның 2 пунктындагы 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
« - җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш иту буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;»;

**2021 елның 1 гыйнварына кадәр 78 статьяның 3 пунктын һәм 83 статьяның 5 пунктын гамәлдә булуын туктатып торырга.**